КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 17 гыйнвар г.Казань № 10

2018 елда Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә өйрәтүне оештыру турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының халыкка социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының матди-техник нигезләрен ныгытуга, картлык буенча һәм инвалидлык буенча иминият пенсияләре алучы эшләмәүче пенсионерларга адреслы социаль ярдәм күрсәтүгә һәм эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә өйрәтүгә бәйле социаль программаларын финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2011 ел, 10 июнь, 456 нчы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2018 елда Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә өйрәтүне оештыру тәртибен;

2018 елда Татарстан Республикасының эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә өйрәтүгә бәйле социаль программасын тормышка ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелә торган субсидияне тоту тәртибен.

2. Татарстан Республикасының Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгын 2018 елда Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә өйрәтүне оештыру өчен җаваплы Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы итеп билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 17 гыйнвар, 10 нчы
карары белән расланды

2018 елда Татарстан Республикасында яшәүче
эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә өйрәтүне оештыру
тәртибе

1. Бу 2018 елда Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә өйрәтүне оештыру тәртибе (алга таба – Тәртип) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының халыкка социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының матди-техник нигезләрен ныгытуга, картлык буенча һәм инвалидлык буенча иминият пенсияләре алучы эшләмәүче пенсионерларга адреслы социаль ярдәм күрсәтүгә һәм эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә өйрәтүгә бәйле социаль программаларын финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2011 ел, 10 июнь, 456 нчы карары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасының 2014 – 2020 елларга «Өлкән яшьтәге гражданнарның тормыш сыйфатын яхшырту» ярдәмче программасы нигезендә өлкән яшьтәге затларның дәүләт мәгълүмат ресурсларыннан файдалана алуын тәэмин итү максатларында эшләнде һәм 2018 елда Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә өйрәтүне оештыру тәртибен билгели.

2. Тәртип нигезендә Татарстан Республикасында яшәүче өлкән яшьтәге затлар (хатын-кызлар өчен 55 яше тулган һәм ир-атлар өчен 60 яше тулган затлар) арасыннан картлык буенча һәм инвалидлык буенча иминият пенсияләре алучы эшләмәүче пенсионерлар (алга таба – эшләмәүче пенсионерлар) түләүсез нигездә компьютер белеменә өйрәнергә хокуклы.

3. Татарстан Республикасы территориясендә эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә өйрәтүне оештыру өчен җаваплы Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы (алга таба – вәкаләтле орган) эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә өйрәтү чараларын тормышка ашыру өчен җаваплы ведомство буйсынуындагы учреждениеләр арасыннан дәүләт казна учреждениесен (алга таба – учреждение) һәм эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә өйрәтү чараларын тормышка ашыру учреждениесе функцияләрен билгели.

4. 2018 елда Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә өйрәтү чараларын финанслау түбәндәгеләр исәбеннән гамәлгә ашырыла:

2018 елда Татарстан Республикасының эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә өйрәтүгә бәйле социаль программаларын тормышка ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелә торган субсидияләр;

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы.

5. Эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә өйрәтү программасы түбәндәге темаларны өйрәнүне күздә тота:

шәхси компьютерлар турында белешмәләр;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, электрон почта һәм тавышлы аралашу чаралары белән эшләү турында белешмәләр;

WINDOWS операцион системасында эшләүнең төп принциплары;

Microsoft Word текст редакторын файдалануның төп принциплары;

мәгълүмат киоскларыннан, түләү терминалларыннан файдалану, электрон рәвештә дәүләт хезмәтләреннән файдалана алу мөмкинлекләре турында белешмәләр.

6. Компьютер белеменә өйрәтү учреждение белән дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт контракты (алга таба – дәүләт контракты) төзегән белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиясе булган мәгариф оешмасы (алга таба – мәгариф оешмасы) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

7. Компьютер белеменә өйрәтүгә кабул итү өчен гариза бирүче, 2018 елның 1 октябреннән дә соңга калмыйча, мәгариф оешмасына кәгазьдә яки электрон төрдә, шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгын теркәп, ирекле рәвештә язылган компьютер белеменә өйрәтү турында гариза (алга таба – гариза) тапшыра.

Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

шәхесне раслый торган документ күчермәсе;

хезмәт кенәгәсе күчермәсе.

8. Гариза бирүчегә карата компьютер белеменә өйрәтү буенча белем бирү хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

гариза бирүче тарафыннан Тәртипнең 7 нче пунктындагы өченче – дүртенче абзацлары белән күздә тотылган документлар тапшырылмау;

гариза бирүче тарафыннан дөрес булмаган белешмәләр тапшырылу;

гариза бирүче Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән гражданнар категориясенә карамау.

9. Компьютер белеменә өйрәтүгә гариза бирүчеләрне кабул итү гаризалар һәм Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән документлар кергән чират тәртибендә һәм әлеге максатлар өчен бүлеп бирелгән бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

10. Мәгариф оешмасы төзелгән дәүләт контракты нигезендә:

Татарстан Республикасы халкына массакүләм мәгълүмат чаралары аша компьютер белеменә өйрәнүгә хокук булу турында мәгълүмат бирүне гамәлгә ашыра;

гаризалар кабул итүне һәм аларны кергән көндә теркәүне гамәлгә ашыра;

гариза теркәлгән көннән биш эш көне эчендә компьютер белеменә өйрәтү буенча белем бирү хезмәте күрсәтү һәм гариза бирүчене уку төркемен төзү өчен гражданнар исемлегенә кертү турында яки мондый белем бирү хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм гариза бирүчегә гаризада күрсәтелгән ысул ярдәмендә кабул ителгән карар турында мәгълүмат хәбәр итә;

компьютер белеменә өйрәтү буенча белем бирү хезмәте күрсәтү турында карар кабул ителгән гариза бирүчеләр арасыннан исемлекләр һәм уку төркемнәре төзи;

укулар башланганга кадәр ун эш көненнән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә аны уку төркеменә кабул итү турында, уку үткәрелә торган көн, вакыт һәм урын турында хәбәр итә;

дәүләт контрактында каралган белем бирү программасы нигезендә укуны үткәрә;

укуны белем бирү программасында билгеләнгән күләмдә уңышлы тәмамлау шарты белән эшләмәүче пенсионерга уку тәмамланган көндә укуда белем алу турындагы билгеләнгән үрнәктәге документны бирә;

учреждениегә дәүләт контракты белән билгеләнгән тәртип, формалар һәм вакытлар нигезендә, әмма 2018 елның 24 декабреннән дә соңга калмыйча, укуда белем алган һәм укуда белем алу турындагы билгеләнгән үрнәктәге документны алган эшләмәүче пенсионерлар саны турында мәгълүмат (белешмәләр) тапшыра.

11. Эшләмәүче пенсионерның компьютер белеменә өйрәнү өчен башка җирлеккә баруына һәм уку чорында башка җирлектә яшәвенә акча түләү яки бу чыгымнарны компенсацияләү эшләмәүче пенсионерның үз акчасы исәбеннән башкарыла.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 17 гыйнвар, 10 нчы
карары белән расланды

2018 елда Татарстан Республикасының эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә өйрәтүгә бәйле социаль программасын тормышка ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелә торган субсидияне тоту
тәртибе

1. Бу 2018 елда Татарстан Республикасының эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә өйрәтүгә бәйле социаль программасын тормышка ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган субсидия акчасын тоту тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының халыкка социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының матди-техник базасын ныгытуга, картлык буенча һәм инвалидлык буенча иминият пенсияләре алучы эшләмәүче пенсионерларга адреслы социаль ярдәм күрсәтү һәм эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә өйрәтүгә бәйле социаль программаларын финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2011 ел, 10 июнь, 456 нчы карары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары нигезендә Россия Федерациясе Пенсия фонды акчасын нәтиҗәле һәм максатчан файдалану максатларында эшләнде һәм 2018 елда Татарстан Республикасының эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә өйрәтүгә бәйле социаль программасын тормышка ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелә торган субсидия акчасын (алга таба – субсидия) тоту тәртибен билгели.

2. Субсидия Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә (алга таба – Казначылык) Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына ачылган бердәм исәпкә күчерелә.

3. Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы Казначылыктан субсидия акчасы керү турында мәгълүмат алганнан соң өч эш көне эчендә Казначылыкка 2018 елда Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә өйрәтүне оештыру өчен җаваплы Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына (алга таба – вәкаләтле орган) финанслауның иң чик күләмнәренә җиткерүгә чыгымнар исемлеген кертә.

4. Вәкаләтле орган субсидия акчасы исәпкә кергәннән соң биш эш көне эчендә Казначылыкка вәкаләтле орган тарафыннан 2018 елда Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белемнә өйрәтү чараларын тормышка ашыру функцияләре йөкләнгән әлеге орган ведомствосы буйсынуындагы учреждениегә (алга таба – учреждение) финанслауның иң чик күләмнәренә җиткерүгә чыгым исемлеген тапшыра.

5. Акча дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә учреждение һәм мәгариф оешмасы арасында төзелгән эшләмәүче пенсионерларны компьютер белемнә өйрәтү буенча хезмәт күрсәтүләр турындагы дәүләт контракты (алга таба – дәүләт контракты) нигезендә мәгариф оешмасы тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә алга таба түләү өчен учреждениенең Казначылыкта ачылган шәхси исәбенә күчерелә.

6. Учреждение ай саен, хисап аеннан соң килүче айның 10 сына кадәр, вәкаләтле органга Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан билгеләнгән форма буенча социаль программаны финанслашу буенча йөкләмәләрнең Татарстан Республикасы тарафыннан үтәлүен раслый торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру турында хисап һәм финанслар белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра.

7. Вәкаләтле орган ай саен, хисап аеннан соң килүче айның 15 енә кадәр, Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча социаль программаны финанслашу буенча йөкләмәләрнең Татарстан Республикасы тарафыннан үтәлүен раслый торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру турында хисап һәм финанслар белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра.

8. Вәкаләтле орган һәм учреждение тапшырыла торган хисаплардагы белешмәләрнең дөреслеге һәм субсидияне нәтиҗәле һәм максатчан файдалану өчен законнар нигезендә җавап бирә.

9. Хисап финанс елында файдаланылмыйча калган субсидия вәкаләтле орган тарафыннан хисап елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемнәнә кире кайтарылырга тиеш.

10. Вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашыра.

11. Субсидияне максатчан файдалануны тикшерүдә тоту вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

12. Учреждениегә бирелгән һәм максатчан билгеләнештә файдаланылмаган акча вәкаләтле органның тиешле таләбен алган көннән 10 көн эчендә аның Казначылыктагы шәхси исәбенә кире кайтарылырга тиеш.

Учреждение тарафыннан акчаны кире кайтару өчен билгеләнгән вакыт бозылганда, вәкаләтле орган кире кайтару вакыты чыккан көннән биш көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына законнар белән билгеләнгән тәртиптә түләттерү буенча чаралар күрә.

13. Вәкаләтле орган Тәртипнең 12 нче пункты нигезендә үзенең Казначылыктагы шәхси исәбенә кергән акчаны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылыктагы шәхси исәбенә әлеге акча кергән вакыттан ике эш көне эчендә күчерүне тәэмин итә.

14. Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы өч эш көне эчендә субсидияне Россия Федерациясе Пенсия фондына кире кайтаруны гамәлгә ашыра.